| | |
|---|---|
| Республика Татарстан Совет<br>Абалачевского сельского поселения<br>Менделеевского муниципального<br>района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Менднлеев муниципаль районы<br>Абалач авыл<br>Җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Решение<br>2021 елның 12 апреленнән | Карар<br>№ 33 |

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 мартындагы 20 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында белешмәләр бирү турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 8 пунктындагы 3 пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары Л.А. Шияпова